КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 2 май г.Казань № б-1012

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 13 март, б-621 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Республика башкарма хакимият органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, республика башкарма хакимият органнары булмаган Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарына, Форумны оештыруга һәм үткәрүгә җәлеп ителгән теләсә нинди оештыру-хокук рәвешендәге оешмаларга – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Цифрлы үсешкә ярдәм күрсәтү ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасына күргәзмә экспозициясен оештыручы һәм Форумның эшлекле программасын оештыруда катнашучы булуны йөкләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Форум чаралары үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен тәэмин итүдә Оештыручыларга ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге боерык белән расланган KAZAN DIGITAL WEEK – 2023 халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турындагы нигезләмәнең 1.1, 5.1.3 һәм 6.4 пунктларында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган KAZAN DIGITAL WEEK – 2023 халыкара форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан Н.Р.Залаковны, А.Ә.Тимерхановны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

«Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенең мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль транспорт системалары департаменты директоры Игорь Валерьевич Антроповны (килешү буенча);

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының Кинематография һәм цифрлы үсеш департаменты директоры урынбасары Алексей Васильевич Наймушинны (килешү буенча);

«Болгар ислам академиясе» югары белем бирү рухи мәгариф оешмасының мөселман дини оешмасы ректоры Фәрхәт Госман улы Хөснетдиновны (килешү буенча);

«Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенең интеллектуаль транспорт системалары һәм цифрлаштыру идарәсе рәисе урынбасары Виктория Вячеславовна Эркенованы (килешү буенча);

«Черников Максим Юрьевич» сүзләрен «Черников Михаил Юрьевич» сүзләренә алмаштырырга;

Тимур Лазович Алибаевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин